| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**01.11.2024** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 4102** |

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 2 сентябрендәге «Зеленодольск муниципаль районының хисапчы хезмәтләре хезмәткәрләренә хезмәте өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» 1780 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Хисапчы хезмәтләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын камилләштерү максатыннан, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 2 сентябрендәге «Зеленодольск муниципаль районының хисапчы хезмәтләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» 1780 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Зеленодольск муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтерия» муниципаль казна учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында нигезләмәнең 1 нче кушымтасындагы 3 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. «Зеленодольск муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтерия» МКУ хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады түбәндәге күләмдә билгеләнә:

| Хезмәткәр вазыйфалары | Вазыйфаи оклад, сум |
|---|---|
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 37 800 |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 36 200 |
| Бүлек башлыгы | 30 500 |
| Бүлек башлыгы урынбасары | 27 000 |
| Әйдәп баручы хисапчы | 26 800 |
| Әйдәп баручы икътисадчы | 26 800 |
| Сатып алулар өлкәсендә әйдәп баручы белгеч | 26 800 |

| | |
|---|---|
| Әйдәп баручы ревизор | 26 800 |
| Хисапчы | 25 300 |
| Ревизор | 25 300 |
| Сатып алулар өлкәсендә белгеч | 25 300»; |

2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы бухгалтерлык хезмәтләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» 2019 елның 2 сентябрендәге 1780 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 30 маендагы 1419 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. ЗМР Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлегенә әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының (http://pravo.tatarstan.ru) рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) мәгълүмат сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин